МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.03.2019 г.Казань № 158

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 28 мартында 5492 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгы белән расланган Укудан буш вакытларында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькәчә булган эшсез гражданнарны Татарстан Республикасында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Укудан буш вакытларында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькәчә булган эшсез гражданнарны Татарстан Республикасында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 10 июнендәге 337 номерлы, 2018 елның 26 сентябрендәге 904 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Укудан буш вакытларында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькәчә булган эшсез гражданнарны Татарстан Республикасында вакытлыча эшкә урнаштыруны

оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктның өченче абзацында «картлык буенча иминият пенсиясенә, шул исәптән картлык буенча билгеләнә торган иминият пенсиясенә вакытыннан алда, чыгу хокукын бирә торган яшькә җиткәнче ике ел алдан» сүзләрен «картлык буенча иминият пенсиясенә, шул исәптән картлык буенча билгеләнә торган иминият пенсиясенә вакытыннан алда, чыгу хокукын бирә торган яшькә җиткәнче биш ел дәвамында» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктта «http://www.uslugi.tatarstan.ru» сүзләрен «http://www.gosuslugi.ru» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» сүзләреннән соң «(http://www.uslugi.tatarstan.ru)» сүзләрен өстәргә;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы белгечләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министр исеменә тапшырыла.

Министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.».

Министр Э.Ә. Зарипова